ГАПОУ «Арский педагогический колледж им. Г. Тукая»
ДАҺБУ «Г. Тукай ис. Арча педагогия көллияте»

#СТУДЕНТЛАРДӨНЬЯСЫ

# Көллият сулышы

№ 7

04/2023



# Я Ң А Л Ы К Л А Р

Арча районының “Кычыткан” командасы “Әйдә ШаяРТ” татар Лигасында лаеклы чыгыш ясады!
Команда 2 урынны алып, ярымфиналга үтте. Алга таба җиңүләр һәм иҗади уңышлар теләп калабыз!



---



20 апрель көнне көллиятебездә Г.Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры кунакта булды. Алар безгә “Зәйтүнәкәй” спектаклен тәкъдим иттеләр. Тукай-Зәйтүнә мәхәббәтен чагылдырган әсәр һәркем тарафыннан җылы кабул ителде. Артистлар көлдерделәр дә, елаттылар да, уйланырга да мәҗбүр иттеләр. Афәрин!

---

26 нчы апрель көнне Г.Тукай исемендәге Әтнә авыл хуҗалыгы техникумында Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмалары студентлары арасында үткән бөек татар шагыйре Г.Тукайга багышланган “Тукай төрле телләрдә” дип исемләнгән республикакүләм шигырь укучылар бәйгеседә студентларыбыз Мәҗитова Галия (татар телендә шигырь сөйләүчеләр арасында) һәм Хәкимуллина Илүзә (рус телендә шигырь сөйләүчеләр арасында) 1 урын яуладылар. Котлыйбыз!






# “АРЧА ЕГЕТЛӘРЕ” ХАЛЫК ВОКАЛЬ АНСАМБЛЕ

Арча ягы – мәшһүр Тукай ватаны – әдәбиятка, җыр-моңнарга гашыйк күп шәхесләргә, гаҗәеп талантлы кешеләргә бай як. Көллиятебездәге “Арча егетләре” халык вокаль ансамбле дә шундыйлардан.

“Егетләр” ансамблен 1970-71 нче уку елында Арча педучилищесының җыр, музыка укытучысы Марсель Фәйзрахманов оештыра. 1971 нче елның 23 нче февраленә багышланган тантанада Арча педучилищесының актлар залында ансамбль Фәтхерахман Әхмәдиевның Роберт Әхмәтҗанов сүзләренә язылган “Солдатлар” җырын башкара. Бу көн тарихка “Егетләр” ансамбленең туган көне булып кереп кала.




Менә инде 50 елдан артык “Арча егетләре” халык вокаль ансамбле халкыбызга тугры хезмәт итә. Бүгенге көндә аны Арча педагогия көллиятенең музыка укытучысы Диләрә Хәйдәрҗанова җитәкли. Алар халыкара, республикакүләм төрле бәйгеләрдә һәм фестивальләрдә актив катнашып, призлы урыннар яулыйлар. Мәсәлән, 2022 нче уку

елында Кабардино-Балкарияга барып, “Нальчик” шәһәрендә Татарстанның данын яклап, чыгыш ясадылар. Шулай ук “Милли Хәзинә” бәйгесендә 2 нче урын, 2023 нче елда Әлмәт шәһәрендә “Идел буе халыклары” фестивалендә 2 нче урын яуладылар.



Быел “Арча егетләре” халык вокаль ансамбле “Созвездие Йолдызлык” фестиваленең район этабында катнашып, 1 нче урынга лаек булдылар һәм Пирамидага хәтле барып життеләр. Егетләр анда да үзләрен сынатмадылар: 1 нче урынны кулларыннан ычкындырмадылар.

Татар халык артисты Габдулла Рахимкулов исемендәге халыкара вокалистлар конкурсында да 1-2 нче урыннар яуладылар. Яратып катнаша торган “Наш дом Татарстан” фестивалендә дә ел саен гала-концертка үтәләр. М.Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында, И.Шакиров




исемендәге концертлар залында, Р.Сафиуллин исемендәге Ачык татар халык җыр һәм музыка сәнгате фестивалендә дә ел саен актив катнашып киләләр. Нинди генә чара, конкурс булса да алар бер дә читтә калмыйлар. Чыгышларын тамашачы яратып көтеп ала, алкышларга күмә. Алга таба да аларга иҗат уңышлары, зур үрләр яулауларын теләп калам.

**Зиннәтова Алия, 221 нче төркем студенты**





# Апрель булып җиргә Тукай килә...




26 апрель – халык шагыйре, милләтебезнең йөз аклыгы булган бөек шәхесебез – Габдулла Тукай туган көн. Бу датаны Татарстан һәм дөньяның төрле җирләренә сибелеп яшәгән татар халкы Туган тел көне, Шигърият бәйрәме буларак зурлап билгеләп үтә.

Габдулла Тукай исемен йөрткән көллиятебез өчен бу – икеләтә бәйрәм. 26 нчы апрельдә Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятендә бөек шагыйребезгә 137 ел тулуга багышланган митинг үткәрелде. Чараны көллиятебез директоры Гарипова Гөлнара Фидаил кызы ачып җибәрде. Шулай ук шагыйрьнең якташы, рус теле укытучысы Галимуллина Наилә Зариф кызы истәлекләре белән уртаклашты. Митингта беренче курс студентлары катнашты. Алар Г.Тукайның шигырьләрен төрле телләрдә сөйләп, бәйрәмне тагын да җанландырдылар. Чара бер сулышта узды, Габдулла Тукай сүзләренә язылган “Туган тел” җырын аягүрә басып башкару белән тәмамланды. Аннары көллиятебезнең студентлары бөек шагыйребезнең һәйкәленә чәчәкләр куйдылар.






**Шиһабеддинова Г.Х.**

## Тукайның шәхси әйберләре

Апрель ае – Тукай ае, шигърият ае. Бөек шагыйребез иҗатын өйрәнүне дәвам итеп, Г.Тукай музеенда саклана торган шагыйрьнең шәхси әйберләре белән танышып китик.

**Габдулла Тукайның юл кәрзине.**



Камыштан үрелгән юл кәрзине шагыйрьне күп җирләргә озата йөргән. Институтка кәрзинне Казанда яшәүче композитор Мансур Мозаффаров китергән.

**Кара бәрхет түбәтәй.**



Габдулла Тукайның кара бәрхет түбәтәен 1987 елда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан музей фондына тапшыралар. Замандашлары искә алганча, 1908 елгы фотосурәтендә Габдулла Тукай шушы түбәтәйне киеп төшкән. Аны шагыйрьгә нәшир Гыйльметдин Шәрәф бүләк иткән. Әлеге нәширнең “Үрнәк” типографиясендә Габдулла Тукайның шактый китаплары бастырылган.

**Габдулла Тукайга Газизә апасына бүләк иткән тартмачык.**



Шагыйрь Уральск шәһәрендә яшәгәндә үзенең беренче гонорар акчасына үги апасы Газизә Зәбировага фаянстан ясалган тартмачык бүләк итә. Аны музейга 1987 елда Газизә Зәбированың улы Хөсәен Зәбиров тапшыра.

**Габдулла Тукайның җиң каптырмалары.**



Шагыйрьгә көмеш җиң каптырмаларын Әхмәтгәрәй Хәсәни бүләк иткән. Бу җиң каптырмаларын музейга 1987 елда Казанда яшәүче рәссам А.Низаметдинов тапшыра. Аларны исә рәссамга 1950 нче елларда Зәйнәп Хәсәния биргән. Зәйнәп ханым “Аң” журналы җаваплы сәркатибе вазифасында эшләгән, ә ире Әхмәтгәрәй Хәсәни журналның мөхәррире булган. 1911–1912 елларда Әхмәтгәрәй Хәсәни Австрия һәм Германиягә бара, җиң каптырмаларын ул шул сәяхәтеннән алып кайткан булса кирәк.

**Габдулла Тукайның кара савыты.**

Бакырдан эшләнгән кара савытын Габдулла Тукайга 1912 елның язында Санкт–Петербургка баргач укучы балалар бүләк итә. Савытның аслыгында ау эте утыра, янында аучының киемнәре һәм мылтыгы – алары зур эшләпә белән капланган. 1949 елда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан музей фондына тапшыралар.



Институтка бу ядкарьне композитор Мансур Мозаффаров китерә. 1945 елда кара савыты композиторның әнисе Мәһруй Мозаффариядә сакланган. Алар Тукай белән яхшы таныш булганнар. Мәһруй Мозаффариянең кияве Әхмәт Урманчиев “Ялт–Йолт” сатирик журналының мөхәррире була, ә Тукай – җаваплы сәркатип. Шагыйрь вафатыннан соң кара савыты Әхмәт Урманчиевтә саклана, әнисенең васыятен үтәп Мансур Мозаффаров ядкарьне институтка тапшыра.

**Габдулла Тукай вафатыннан соң йөзеннән төшереп алынган гипс битлек.**



Габдулла Тукай 1913 елның 15 апрелендә (иске стиль буенча 2 апрель) Казанның Клячкин хастахнәсендә вафат була. Бу битлекне 1957 елда Алматада яшәүче А.Мөлеков дигән кеше музейга китерә. Аның сүзләренчә, әлеге битлекне аңа Оренбург шәһәрендә 1930 елда нәшир Гыйльметдин Шәрәфнең бертуганы Борһан Шәрәф тапшырган.


**Габдулла Тукайның Зиннәтулла бабасы Корьәне.**



Габдулла Тукайның әнисе ягыннан бабасы Зиннәтулла хәзрәт Әмировның Корьәне Татарстан Милли музее фондында саклана. Корьән Санкт–Петербурга 1868 елда бастырылган, 347 биттән тора.

**Материалны татар теле һәм әдәбияты укытучысы Алия Гыйләҗева әзерләде**

# ТУКАЙ ЭМОДЗИЯЛАРЫ



**БЕР-БЕРЕБЕЗ БЕЛӘН СМАЙЛИКЛАР АША АРАЛАШУ КҮПТӘН ИНДЕ ГАДӘТИ ХӘЛГӘ ӘВЕРЕЛДЕ. КАЙЧАКЛАРДА СҮЗЛӘР ДӘ ЯЗЫП ТОРЫРГА КИРӘК ТҮГЕЛ ХӘТТА. ӘҢГӘМӘДӘШЕБЕЗНЕҢ НӘРСӘ ӘЙТЕРГӘ ТЕЛӘГӘНЕН ӘЛЕГЕ БИЛГЕЛӘР ЯРДӘМЕНДӘ ДӘ БИК ЯХШЫ АҢЛЫЙБЫЗ. ШУҢА КҮРӘ “ЭМОДЗИЯЛАР БЕЛӘН ЭШ”НЕ КАТЛАУЛАНДЫРЫРГА УЙЛАП, АЛАР АРТЫНА БАРЫБЫЗГА ДА ЯХШЫ ТАНЫШ БӨЕК ШАГЫЙРЬ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ИСЕМНӘРЕН ЯШЕРДЕК. СИН ДӘ ҮЗЕҢНЕ СЫНАП КАРА, ҖАВАПЛАРНЫ ЭЗЛӘП ТАП!**

**Төзеде:** Халикова К., Хәкимова Я. (213 нче төркем студентлары)

**Редколлегия:** Шиһабеддинова Г.Х.

Гыйләҗева А.Ф., Зиннәтова А., Халикова К., Хәкимова Я.